| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«16 » февраль 2023г. № 29

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы МБУ «Хуҗалык-эксплуатация конторасы» җитәкчеләренә, белгечләренә һәм эшчеләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында

«Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 30 маендагы 412 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы МБУ «Хуҗалык-эксплуатация конторасы» җитәкчеләренә, белгечләренә һәм эшчеләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«16» 02 2023 № 29
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы МБУ «Хуҗалык-эксплуатация конторасы» җитәкчеләренә, белгечләренә һәм эшчеләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

**Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы МБУ «Хуҗалык-эксплуатация конторасы» җитәкчеләренә, белгечләренә һәм эшчеләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы МБУ «Хуҗалык-эксплуатация конторасы» эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм вазыйфаи окладларның күләмен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

Хезмәткәргә хезмәт хакы хезмәт хакы түләү турындагы нигезләмә нигезендә хезмәт шартнамәсе (хезмәт шартнамәсенә өстәмә килешү) белән билгеләнә, анда хезмәткә түләү шартлары, башкарыла торган эшләрнең квалификациясенә һәм катлаулылыгына карап, календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү өчен хезмәт хакы ставкасының беркетелгән күләме, шулай ук кызыксындыру һәм компенсация характерындагы түләүләр күләме һәм шартлары күрсәтелә.

**I бүлек. Бердәм тариф челтәре буенча хезмәт өчен түләү**

1.1. Теләче муниципаль районы МБУ «Хуҗалык-эксплуатация конторасы» (алга таба - МБУ «ХЭК») җитәкчеләренең, белгечләренең һәм эшчеләренең хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, премиядән, өстәмә түләүдән, зыян өчен түләүләрдән тора.

1.2. МБУ «ХЭК» җитәкчеләренең, белгечләренең һәм эшчеләренең вазыйфаи окладлары әлеге нигезләмә нигезендә түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

| Бердәм тариф челтәренә түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тарифлы ставкалар (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,00 | 15 279 |
| 2 | 1,0159 | 15 522 |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | 1,0323 | 15 773 |
| 4 | 1,0480 | 16 012 |
| 5 | 1,0656 | 16 281 |
| 6 | 1,0827 | 16 543 |
| 7 | 1,1010 | 16 822 |
| 8 | 1,1187 | 17 093 |
| 9 | 1,1363 | 17 362 |
| 10 | 1,1553 | 17 652 |
| 11 | 1,1736 | 17 931 |
| 12 | 1,1933 | 18 232 |
| 13 | 1,2129 | 18 532 |
| 14 | 1,2325 | 18 831 |
| 15 | 1,2528 | 19 142 |
| 16 | 1,2738 | 19 462 |
| 17 | 1,2947 | 19 782 |
| 18 | 1,3163 | 20 112 |

1.3. Премияләр һәм башка бүләкләү түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары (премия бирү турындагы Нигезләмә) белән билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре хезмәткәрләргә билгеле бер вакыт аралыгында хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен күләмнәре хезмәт нәтиҗәләре буенча хезмәткәрләргә 16,66 % тәшкил итә (елына ике вазыйфаи хезмәт хакы).

1.4. Хезмәт хакы ставкасына айлык стимуллаштыручы процент өстәмәләре әлеге нигезләмә нигезендә башкарыла торган эшләрнең дәрәҗәсенә һәм катлаулылыгына карап, җитәкче боерыгы белән түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

| Вазыйфа | Өстәмә түләү күләме |
|---|---|
| Башлык | 14500,00 |
| Башлык урынбасары | 1500,00 |
| Диспетчер | 2500,00 |
| Электрик | 5600,00 |
| Автомобиль йөртүче | 5000,00 |
| Сатып алулар буенча белгеч | 8600,00 |

| | |
|---|---|
| Секретарь | 2000,00 |
| Слесарь сантехник | 6800,00 |
| Юрисконсульт | 1700,00 |
| Комплекслы хезмәт күрсәтү һәм биналарны ремонтлау буенча эшче | 1500,00 |

1.5. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары нигезендә билгеләнә.

Эшчеләргә түбәндәге компенсация түләүләре билгеләнә:

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эштән тыш эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр. Нормаль шартлардан читләшкән эшләүче эшчеләрнең хезмәтенә (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эштән тыш эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) түләү фактта эшләгән сәгатьләр өчен вазыйфаи окладтан 20 % тәшкил итә;

- авыр эшләрдә, зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләргә түләү.

1.6. Компенсация характерындагы түләүләр, авыр эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә, хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч шартлары булган эшләрдә эшләүчеләргә, хезмәт законнарында билгеләнгән күләмдә хезмәт шартларын махсус бәяләү (яисә эш урыннарын гамәлдәге аттестацияләү) нәтиҗәләре нигезендә билгеләнә. Хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт хакының 4 % тәшкил итә.

## II бүлек. ХТЯС (НСОТ) буенча йөртүчеләрнең хезмәтенә түләү. Гомуми тармак эшчеләр һөнәрләренең профессиональ квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Гомуми тармак эшчеләр һөнәрләренең профессиональ квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары, Теләче муниципаль районы МБУ «ХЭК» машина йөртүчеләренең вазыйфаи окладлары әлеге нигезләмә нигезендә түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айга база окладлы күләме, сум |
|---|---|
| "Икенче дәрәҗәдәге эшче һөнәрләре" профессиональ квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 618 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 16 501 |

2.2. Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәләренә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр;
- премия һәм башка бүләкләү түләүләре.

Хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр хезмәткәрләргә теркәлгән күләмдә 7000,0 сумнан алып 10000,0 сумга кадәр, учреждение җитәкчесе боерыгы нигезендә бирелә.

Премиаль һәм башка кызыксындыру түләүләре хезмәткәрләргә билгеле бер вакыт өчен билгеләнә.

Премия һәм башка бүләкләү түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының локаль актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

Гомуми тармак эшчеләр һөнәрләренең профессиональ квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең премия түләүләренә каралган күләм төп вазыйфа һәм төп эш урыны буенча хезмәткәрләргә хезмәт хакының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

## III бүлек Компенсация сыйфатындагы түләүләр

3.1. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;
- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү;
- компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары, әлеге Нигезләмә, булган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

Хезмәт өчен түләү фонды күләме зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә вазыйфаи окладның 4 % тәшкил итә.

Эшләр белән идарә итүче И.Т. Һадиев